**ГЛАВА КИРБИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422626 с. Кирби,
ул. Горького, д.26а
тел: 4-38-16

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ХӘЕРБИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**
422626 Хәерби авылы,
Горкий урамы, 26а нчы йорт,
тел: 4-38-16

---

2025 елның 8 октябре 3 номер

# БОЕРЫК

**16:24:110201:6 кадастр номерлы җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында боерык проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү хакында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 39 маддәсе, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Хәерби авыл җирлеге Уставы, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының 2018 елның 12 декабрендәге 17 номерлы Хәерби авыл җирлеге Советы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Хәерби авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә, җир кишәрлекләренең һәм капиталь төзелеш объектларының хокук ияләренең тормыш эшчәнлеге, хокукларының һәм законлы мәнфәгатьләренең уңай шартларын үтәү максатларында, КАРАР ИТӘМ

1. Татарстан Республикасы, Лаеш районы, Хәерби авылы, Совет ур., 203 адресы буенча урнашкан индивидуаль торак төзелеше зонасында (Ж1), кадастр номеры 16:24:110201:6 булган җир кишәрлегендә шартлы рәвештә рөхсәт ителгән «Шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен» нән файдалануның рөхсәт ителгән “Кибетләр”төренә күчерү.
2. Билгеләргә:

2.1 Гавами тыңлауларны үткәрү датасы һәм вакыты - 2025 елның 28 октябрь 15 00 сәгатьтә.

2.2 Үткәрү урыны - Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Хәерби авыл җирлеге башкарма комитеты, адресы: 422624, Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Хәерби авылы, Горький ур., 26 йорт.

2.3 Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рәвештә рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турындагы боерык проекты буенча тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Хәерби авыл җирлеге башкарма комитетына түбәндәге адрес буенча тапшырырга: 422624, Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Хәерби авылы, Горький ур., 26 йорт.

2.4. Чыгыш ясау хокукы белән гавами тыңлауларда катнашуга гаризалар бирү вакыты 2025 елның 24 октябренә кадәр.

3. Әлеге карарны “Кама ягы”(«Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Хәерби авыл җирлегенең махсус мәгълүмати стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Хәерби**
**авыл җирлеге Советы рәисе** **Р.К. Зинәтуллин**